БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«23» 04 2025 ел

**КАРАР**

№ 140

«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» МКУ җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм аның шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2025 елның 04 апрелендәге 03-12/2212 номерлы хаты нигезендә Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Балтач районы башкарма комитетының 2019 елның 16 маендагы 200 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» МКУ җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм аның шартлары турындагы Нигезләмәгә (2020 елның 04 декабрендәге 348 номерлы, 2022 елның 24 ноябрендәге 333 номерлы, 2024 елның 03 маендагы 141номерлы, 2024 елның 16 октябрендәге 251 номерлы карарлар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) 1 нче кушымта нигезендә түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны интернетта - «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы (baltasi.tatarstan.ru) составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2025 елның «23» 04
140 номерлы карарына
кушымта

**«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Үзәкләштерелгән бухгалтериясе» МКУ җитәкчеләренә һәм белгечләренә хезмәт өчен түләүне оештыру һәм аның шартлары турында Нигезләмә**

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» МКУ җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм аның шартлары турындагы әлеге Нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтериясе» МКУ эшчәнлеген оештыруның аерым мәсьәләләрен регламентлаштыра һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгели.

2. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» МКУ җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәт хакы хезмәт окладын, тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмәне, эш киеренкелеге өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмәне, акчалата бүләкләүне, еллык түләүле отпуск биргәндә бер мәртәбә түләнә торган түләүне һәм матди ярдәмне, эш нәтиҗәләре буенча премияләрне үз эченә ала.

3. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» МКУ җитәкчеләре һәм белгечләренең вазыйфаи окладь түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Җитәкче һәм белгечләр вазыйфасы | Вазыйфаи оклад, сум |
|---|---|
| | Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 37 000 |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 34 600 |
| Бүлек башлыгы | 30 500 |
| Әйдәп баручы хисапчы | 27 800 |
| Хисапчы | 26 400 |

Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтериянең штат расписаниесенә җитәкче урынбасары вазыйфасын кертү шарты булып, структурада һәрберсендә 5 берәмлек штат санынннан ким булмаган кимендә 3 бүлек булу тора.

Үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлекләренең штат саны кимендә 5 берәмлектән аз булмаска тиеш.

4. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтериясе» МКУ җитәкчеләренә һәм белгечләренә түбәндәге түләүләр билгеләнә:

1) тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка түбәндәге күләмнәрдә айлык өстәмә:

| Эш стажы | Айлык өстәмә, процент |
|---|---|

| | |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 7 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 10 |
| 15 елдан артык | 15 |

2) эш киеренкелеге өчен вазыйфаи окладка ай саен вазыйфаи окладның 10 проценты күләмендә өстәмә;

3) еллык түләүле отпуск бирелгәндә вазыйфаи окладның 120 проценты күләмендә бер тапкыр бирелә торган түләү.

Әгәр хезмәткәргә календарь ел дәвамында еллык түләүле отпуск бирелмәгән булса, бер тапкыр түләнә торган түләү хезмәт башкарылган вакытка пропорциональ рәвештә исәпләнә һәм декабрьдә түләнә, эштән азат ителгән очракта - соңгы эш коненнән дә соңга калмыйча түләнә.

Эшкә урнашуның беренче елында еллык түләүле отпуск бирелгәндә хезмәткәргә бер тапкыр түләнә торган түләү календарь елда эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә башкарыла. Эшләнгән вакыт эшкә кергән көннән агымдагы елның 31 декабренә кадәр исәпләнә.

4) билгеләнгән хезмәт өчен түләү фонды кысаларында акчалата бүләкләү, матди ярдәм;

5) түбәндәге күләмнәрдә айлык премия:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазыйфалары | Айлык премия, % |
|---|---|
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 45 |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 45 |
| Бүлек башлыгы | 45 |
| Әйдәп баручы хисапчы | 25 |
| Хисапчы | 20 |

Шулай ук бер ай һәм квартал өчен эш нәтиҗәләре буенча премия исәпләнергә мөмкин.

5. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» МКУ җитәкчеләренең һәм белгечләренең еллык хезмәт хакы фонды түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT = \sum_{1}^{n}((O_d + 0{,}3 * O_d) * k) * (1 + t) + \sum_{1}^{n} P * (1 + t);$$

биредә:

$FOT$ - җитәкчеләрнең һәм белгечләрнең еллык хезмәт хакы фонды;

$O_d$ - җитәкчегә һәм белгечкә бер айга вазыйфаи окладлар түләү өчен акча суммасы;

$0{,}3 * O_d$– тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү, эш киеренкелеге өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә, акчалата бүләкләү, еллык түләүле

отпуск бирелгәндә бер мәртәбә түләнә торган түләү, матди ярдәмне күрсәтү өчен түләү суммасы;

P – җитәкчеләрнең һәм белгечләрнең еллык премия фонды (әлеге Нигезләмәнең 3 пунктындагы 5 пунктчасында билгеләнгән шартлардан чыгып билгеләнә);

$n$ - җитәкчеләрнең һәм белгечләрнең штат саны;

$k$ - 12 ай;

$t$ – хезмәт өчен түләү буенча өстәмәләр.